**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№ 15 01 июнь 2015 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр (авыл) җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда үзара эшчәнлеге турында килешүне раслау хакында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 124, 125 һәм 421 статьялары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы карары:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешүне Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2015 елның 9 апрелендәге 11 номерлы карары " дәүләт милке чикләнмәгән һәм авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешү хакында»;

3.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы М.М.Сулейманкин